| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ |
|---|---|---|
| ГЛАВА СТАРОАЛЬМЕТЬЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | | ИСКЕ ӘЛМӘТ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ Иске Әлмәт ав. КАРАР

«13» ноябрь 2021 ел № 2

«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Әлмәт авыл җирлеге Иске Әлмәт авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Иске Әлмәт авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Иске Әлмәт авыл җирлеге башлыгы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2021 елның 25 ноябрендә 10 сәгать 00 минутка Октябрь урамы, 19 нчы йорт адресы буенча урнашкан Иске Әлмәт авылы мәдәният йорты бинасы янында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Әлмәт авыл җирлеге Иске Әлмәт авылы буенча Тукай, Березовая, Дорожная, Моставая урамнарында урнашкан йортларда яшәүчеләр өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын уздыруны билгеләргә
2. 2021 елның 25 ноябрендә 13 сәгать 00 минутка Октябрь урамы, 19 нчы йорт адресы буенча урнашкан Иске Әлмәт авылы мәдәният йорты бинасы янында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Әлмәт авыл җирлеге Иске Әлмәт авылы буенча Октябрь, Полевая, Больничная, Родниковая, Островная урамнарындагы йортларда яшәүчеләргә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча буенча гражданнар җыенының икенче этабын уздыруны билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Әлмәт авыл җирлеге Иске Әлмәт авылында яшәүчеләрнең исемлеген территориаль билге буенча гражданнар җыенын үткәрү өчен бүләргә.
4. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Иске Әлмәт авыл җирлеге Иске Әлмәт авылында халык җыены этапларын үткәрү һәм оештыру белән Иске Әлмәт авыл җирлеге башлыгы һәм Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Иске Әлмәт авыл җирлеге башкарма комитеты тәэмин итә.

5. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Нурлат муниципаль районы Иске Әлмәт авыл җирлеге Иске Әлмәт авылы территориясендә теркәлгән урыны буенча яшәүче, 1 гр. инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан кала балигъ булган һәр кешедән 2022 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме:

- юлларны карап тоту, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Иске Әлмәт авыл җирлеге Иске Әлмәттә торак пункт чикләрендәге юлларда алга таба вак таш җәю өчен грейдер белән тигезләү һәм тыгызлап нигезен күтәрү буенча хезмәтләр;
- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Иске Әлмәт авыл җирлеге торак пункты чикләрендә юл өслеге профилен үзгәртеп вак таш сатып алу, вак таш түшәү өчен хезмәт күрсәтүләр;
- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Иске Әлмәт авыл җирлеге православие зиратын төзекләндерү һәм тирәсен тоту.

« РИЗА» «КАРШЫ».

6. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru., Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында района http://nurlat.tatarstan.ru, Иске Әлмәт авыл җирлегенең Иске Әлмәт авылы мәгълүмат стендларында гражданнар җыены этапларын үткәрү датасына 10 көннән дә соңга калмыйча бастырып чыгарырга (игълан итәргә).

7. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Иске Әлмәт авыл җирлеге башлыгы Хисамов Р.Г.